| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Новобизякинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Яңа Бәзәкә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2024 Яңа Авыл авылы № 51-1

«Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының 20.11.2017 елның 35-2 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының 20.11.2017 елның 35-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2 нче пунктта:

өченче абзацта «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;».

2. Әлеге карар 01.01.2025 елдан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru,

шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы М.С. Салихов